КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 19 декабрь г.Казань № 1167

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе структурасын, хезмәткәрләренең иң чик санын һәм хезмәт өчен түләү фондын раслау турында» 2013 ел, 26 декабрь, 1060 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе структурасын, хезмәткәрләренең иң чик санын һәм хезмәт өчен түләү фондын раслау турында» 2013 ел, 26 декабрь, 1060 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 декабрь, 965 нче; 2017 ел, 16 август, 588 нче; 2018 ел, 14 май, 365 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1303 нче; 2019 ел, 23 июль, 616 нчы; 2020 ел, 23 октябрь, 948 нче, 2021 ел, 30 декабрь, 1364 нче; 2022 ел, 10 октябрь, 1087 нче; 2022 ел, 2022 ел, 20 декабрь, 1377 нче; 2023 ел, 3 февраль, 95 нче; 2024 ел, 11 июль, 551 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренең иң чик санын – 401 берәмлек, шул исәптән дирекциянекен – 217 берәмлек, филиалларныкын – 184 берәмлек итеп, вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча хезмәт өчен түләүнең айлык фондын – 9 452,716 мең сум күләмендә, шул исәптән дирекциянекен – 5 587,129 мең сум, филиалларныкын 3 865,587 мең сум күләмендә билгеләргә.».

2. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин